**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.12.2015 № 929

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 19 гыйнварында теркәлде, № 3167

Татарстан Республикасы Хезмәт,
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының “Татарстан Республикасы Хезмәт,
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгында Татарстан Республикасының
дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын
биләгәндә, дәүләтнең гражданлык хезмәткәрләре
үзләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре
һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында,
шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган
балаларының керемнәре, чыгымнары, милке
һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында
мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфалар
исемлеген раслау турында” 16.03.2015 ел, № 157
боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәткәрләренә куела торган чикләүләр һәм тыюлар, таләпләр үтәлешен һәм коррупцияне булдырмый калуны тәэмин итү максатыннан боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, дәүләтнең гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфалар исемлеген раслау турында” 16.03.2015 ел, № 157 боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә: Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, эштән азат

ителгәндә, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясының чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылык турындагы нигезләмәләрен аңлатырга.”;

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, дәүләтнең гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфаларның Боерык белән расланган исемлеген (алга таба – Исемлек) яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә:

а) дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык редакциясендә бәян ителгән Исемлек белән таныштырырга;

б) бу боерык редакциясендә бәян ителгән Исемлекне өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә тапшырырга.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
16.03.2015 ел, № 157 боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
18.12.2015 ел, № 929 боерыгы редакциясендә) белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, дәүләтнең гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган вазыйфалар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” категориясендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) эшләр идарәчесе;

Министрлыкның бүлек начальнигы;

Министрлыкның муниципаль районадагы (шәһәр округындагы) территориаль органы җитәкчесе;

Министрлыкның бүлек начальнигы урынбасары;

Министрлыкның сектор мөдире;

Министрлыкның муниципаль районадагы (шәһәр округындагы) территориаль органы җитәкчесе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясендәге вазыйфасы – Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры ярдәмчесе.

3. “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең “белгечләр” һәм “тәэмин итүче белгечләр” категорияләрендәге вазыйфалары:

3.1. юридик бүлектә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант. Алар буенча вазыйфаи бурычларны үтәү контрольлек һәм күзәтчелек итү чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота;

3.2. дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч;

3.3. мәгълүмат технологияләре, автоматлаштырылган системаларны

эшләтү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.4. массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.5. планлаштыру, финанслау һәм хезмәткә түләү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.6. контроль-ревизия эше бүлегендә – әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч, 1 разрядлы белгеч;

3.7. дәүләт сатып алулары бүлегендә – әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.8. үсеш һәм тармак программаларын төзү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.9. социаль яклау чаралары методологиясе бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.10. социаль регистрны формалаштыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.11. социаль яклау чаралары аудиты бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.12. техник реабилитация чаралары бирү һәм шифаханә-курорт дәвасы бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.13. пенсиягә өстәмә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.14. социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.15. хезмәт базарын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүне күзәтү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.16. һөнәргә укыту һәм һөнәргә юнәлеш бирү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.17. хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.18. чаралар үткәрүне оештыру бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.19. делопроизводство бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.20. социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.21. социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын идарә итү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч эксперт;

3.22. иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.23. хәйрия эшчәнлеге секторында – әйдәп баручы киңәшче;

3.24. административ-хуҗалык бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.25. җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.26. мобилизацияләү эше һәм гражданнар оборонасы секторында – әйдәп баручы белгеч;

3.27. халык белән эшләү секторында – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.28. Министрлыкның муниципаль районлагы (шәһәр округындагы) территориаль органында – консультант, әйдәп баручы белгеч-эксперт.

---